# КАРАР

2022 елның 24 ноябре № 1

«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплар турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 5 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 2 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезенд 2022 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыен нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Пчелово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һә студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналарда 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Корал Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Росс Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылга затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым керт белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттә мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме
:

- Пчеловод авылында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып ал урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; килешү буенча эшләр һә хезмәтләр өчен түләү;
- Пчеловод авылының Урман урамындагы юлларга вак таш җәю (вак таш сатып ал ташу, җәю); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәл ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Пчеловод авылының артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу; килешү буенч эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Пчеловод авылы чишмәсе янындагы территорияләрне һәм ял зоналары төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормыш ашыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Пчеловод авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу; килешү буенча эшлә һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һә территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып ал килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Пчеловод авылындагы балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту (килеш буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Пчеловод авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнашты килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Пчеловод авылының Урман урамына асфальт җәю һәм вак таш җәеп ремонтла проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәл ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 201 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 118.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 118 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Пчеловод авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныырга.
2. Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Пчеловод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне расларга карар иттек:

:

- Пчеловод авылына урам яктырту лампалары сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- Пчеловод авылының Урман урамына вак таш җәю һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су башняларын, су саклау зоналарын карап тоту, Пчеловод авылын су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү;

- Пчеловод авылында чишмә янында ял итү зоналары, балалар һәм спорт уен мәйданчыклары территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылында зиратны карап тоту;

- Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машинист-тракторчы хезмәте;

- Пчеловод авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;

- Пчеловод авылына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру һәм видеокүзәтү системаларын урнаштыру; видеокамераларны һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;

- Пчеловод авылы Урман урамы юлларына асфальт салу һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылында балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм якын-тирә территорияләрне яктырту; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылында чишмәне төзекләндерү һәм карап тоту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип таныырга.

. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары-Чура авыл җирлеге башлыгы: В.Н. Андреев